**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 13 октябрь № 763

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 303 нче, 2013 ел, 20 август, 585 нче, 2015 ел, 29 сентябрь, 725 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле егерме өченче һәм егерме дүртенче абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне мониторинглау һәм дини һәм милли җирлектәге каршылыкларны алдан кисәтү комплекслы системасы кысаларында мәгълүматны җыюны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыручы һәм мөнәсәбәтләрне җайга салучы органына тапшыруны гамәлгә ашыра;

үз компетенциясе кысаларында экстремистик эшчәнлеккә һәм террорчылыкка каршы торуда катнаша, Агентлыкка беркетелгән объектларның террорчылыкка каршы якланганлыгын тәэмин итә;»;

егерме өченче абзацны егерме бишенче абзац дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин